# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге составына керүче Өченче Бөгелде торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**14.11.2019** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 14 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Өченче Бөгелде авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- зиратны төзекләндерү, коймасын ремонтлау;
- балалар мәйданчыгын төзекләндерү, балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу;
- торак пункт эчендәге юлларны ремонтлау һәм вак таш җәю.»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 71 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 43 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 40 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 3 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Өченче Бөгелде торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Өченче Бөгелде авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- зиратны төзекләндерү, коймасын ремонтлау;
- балалар мәйданчыгын төзекләндерү, балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу;

- торак пункт эчендәге юлларны ремонтлау һәм вак таш җәю.» сорауы буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Аксар авыл җирлеге башлыгы ____________________ Ю.И.Гильманов